ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1.1^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

“4) җирле үзидарә органнарының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген.”;

2) 3.10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.10 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозу**

1. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозган өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга бер меңнән алып бер мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр административ штраф салына.

2. Бозның калынлыгы 7 сантиметрдан кимрәк булганда, су объектлары бозына җәяүләп һәм (яисә) транспортта кергән өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга бер мең биш йөз сумнан алып ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш меңнән алып җиде мең сумга кадәр; юридик затларга илле меңнән алып җитмеш мең сумга кадәр административ штраф салына.";

3) 8.1 статьяда:

а) исемендә "Административ" сүзе алдыннан "Әлеге Кодекста каралган" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ өлеш өстәргә:

"$13^1$. Әлеге статьяның 2, 5, 9 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 2.6, 3.2, 3.4, 3.6, 3.7, 4.4 статьяларында (җирлекләр милкендәге торак булмаган фонд объектларына карата) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары (секретарьлары), шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган җирлекләрнең башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары төзи.";

в) 14 өлештә "13" санын "$13^1$" санына алмаштырырга, "беркетмәләрне" сүзеннән соң "шәһәр округларының, муниципаль районнарның" сүзләрен өстәргә;

г) 15 өлештә "14 өлешендә" сүзләрен "$13^1$, 14 өлешләрендә" сүзләренә алмаштырырга;

д) 16 өлештә "очракта," сүзеннән соң "шәһәр округларының, муниципаль районнарның" сүзләрен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле 8.2 статья өстәргә:

"8.2 статья. **Җирле үзидарә органнарының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары**

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, $19.4^1$ статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) муниципаль районнарда, шәһәр округларында – муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре, аларның беренче урынбасарлары, муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары;

2) җирлекләрдә – җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары (секретарьлары), шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган җирлекләрнең башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 23 июле
№ 64-ТРЗ